РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«7» июля 2020 ел г. Альметьевск № 909

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларында физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә өстәмә ярдәм күрсәтү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 04 октябрендәге 902 номерлы «Спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә өстәмә ярдәм күрсәтү турында» карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә өстәмә ярдәм күрсәтү турында» 2018 елның 04 октябрендәге 902 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 19 апрелендәге 313 номерлы карарын үтәү йөзеннән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларында физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә ел саен өстәмә түләүле отпуск билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларында ел саен өстәмә түләүле отпуск билгеләнә торган физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркемнәре,исемлеген расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнар «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» ведомство буенча тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә».

4. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварында барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Зак. № 305-2000

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма а комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«7» июль 2020 ел №909
карары белән расланган
1 нче кушымта

### Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларында ел саен өстәмә түләүле отпуск билгеләнә торган физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркемнәре исемлеге

| № | Һөнәр исеме | Спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмасының төре | Еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгы, календарь көннәр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Директор | Олимпия резервы спорт мәктәбе | 14 |
| | Директор урынбасары (эшчәнлекләре спорт әзерлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган директорлар урынбасарларыннан тыш) | | 14 |
| | Тренер | | 14 |
| | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты (өлкән инструктор-методист) | | 14 |
| | Физик культура инструкторы | | 14 |
| | Педагог-оештыручы | | 14 |
| | Педагог-психолог | | 14 |
| 2 | Директор | Спорт мәктәбе | 14 |
| | Директор урынбасары (эшчәнлекләре спорт әзерлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган директорлар урынбасарларыннан тыш) | | 14 |
| | Тренер | | 14 |
| | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты (өлкән инструктор-методист) | | 14 |
| | Физик культура инструкторы | | 14 |
| | Педагог- оештыручы | | 14 |
| | Педагог-психолог | | 14 |
| 3 | Директор | Спортивная адаптивная школа | 14 |
| | Директор урынбасары (эшчәнлекләре спорт әзерлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган директорлар урынбасарларыннан тыш) | | 14<br>14 |
| | Тренер | | 14 |
| | Адаптив физик культура буенча тренер-укытучы (адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы) | | 14 |
| | адаптив физик культура буенча инструктор-методист (адаптив | | 14 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | физик культура буенча өлкән инструктор) | | |
| | Педагог- оештыручы | | 14 |
| | Педагог-психолог | | 14 |

Искәрмә:

Тармак белгечләренең һөнәри квалификация төркемнәре нигезендә һөнәр исемнәре күрсәтелгән:

«Физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри-квалификация төркемнәрен раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2012 елның 27 февралендәге 165н номерлы боерыклары белән расланган физик культура һәм спорт;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәрен раслау турында» 2008 елның 05 маендагы 216н номерлы боерыгы белән расланган мәгариф.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева